| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 12.12.2024 | г.Бавлы | № 281 |

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план
чорына Баулы муниципаль районының
социаль-икътисадый үсешенең
төп күрсәткечләре фаразлары турында

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.С. Мингалиеваның «2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләре фаразы турында» докладын тыңлап, фикер алышканнан соң, Баулы муниципаль район Советы билгеләп үткәнчә, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты, шәһәр хезмәтләре, төрле милек формасындагы предприятиеләр белән берлектә, 2024 елда районның икътисади үсешен тәэмин итү буенча халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән билгеле бер эш башкарган.

Баулы муниципаль районының 2024 елгы социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларын анализлау, түбәндәге бәяләү нәтиҗәләрен күрсәтте:

- тулаем территориаль продукт 64,2 млрд. сум тәшкил итә;
- төп капиталга инвестицияләр – 11,9 млрд. сум;
- авыл хуҗалыгы продукциясе күләме – 3,3 млрд. сум;

- төяп җибәрелгән продукция, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме – 17,1 млрд. сум.

Халыкка түләүле хезмәтләр, район һәм шәһәрнең предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан, 374,0 млн. сум күләмендә күрсәтеләчәк.

Санап үтелгән параметрлардан һәм 2024 елда Баулы муниципаль районының үсеш тенденцияләреннән чыгып, 2025 елга һәм 2026-2027 елларга Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы төзелде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда социаль-икътисадый үсешнең якынча йомгаклары турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (1 кушымта).

2. Баулы муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларын расларга (2 кушымта).

3. Милекнең барлык формадагы сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләре үтәлешен тәэмин итәргә;

- эшчәнлекне җитештерү куәтләреннән нәтиҗәле файдалануга юнәлтергә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга, хезмәт шартларын яхшыртырга һәм эшләүчеләрнең сәламәтлеген сакларга, хезмәт хакын вакытында түләүне тәэмин итәргә, эш урыннарын кыскартуга юл куймаска;

- реаль хезмәт хакын күтәрү буенча чаралар күрергә һәм аның дәрәҗәсен хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән түбәнрәк төшерүгә юл куймаска.

4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына:

- тырышлыкны халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтеп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә;

- бирелгән мөмкинлекләр һәм икътисадый үсеш перспективалары кысаларында бюджет челтәрен оптимальләштерү, энергияне сак тоту һәм энергия сыйдырышлылыкны киметү, социаль өлкә, торак-коммуналь хуҗалык тармакларында бюджеттан тыш юнәлешләрне үстерү буенча чаралар күрергә.

5. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык сораулары буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Баулы
муниципаль район Советының
2024 елның 12 декабрендәге
281 номерлы карарына
1 кушымта

# 2024 елның узган чорында Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше һәм 2024 елда Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең көтелгән НӘТИҖӘЛӘРЕ

| Күрсәткечләр | 2024 гыйнвар-июнь | 2024 бәя бирү |
|---|---|---|
| I. Макроикътисадый күрсәткечләр | | |
| 1. Тулаем территориаль продукт (төп бәяләрдә), млн. сум. | - | 64 241,6 |
| 2. Төяп озатылган продукция (эшләр, хезмәтләр) күләме, млн. сум. | 9046,4 | 17136,7 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, узган елга карата % | 98,2 | 100,5 |
| 4.Барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | - | 3298,1 |
| 5.Финанслауның барлык чыганаклары исәбенә төп капиталга инвестицияләр күләме, млн. сум. | 6163,7 | 11867,2 |
| 6. Торак йортларны файдалануга тапшыру, мең кв. м | 6,966 | 13,0 |
| 7.Кече һәм урта предприятиеләрнең, микропредприятиеләрне дә кертеп, әйләнеше, млн. сум. | - | 3890,1 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 2665,2 | 5804,4 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (әлеге чор ахырына), мең кеше | 0,28 | 0,3 |
| 10. Икътисадый актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,15 | 0,16 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | |
| 1. Айга уртача җан башына керемнәр, сумнарда | 46256,1 | 46791,2 |
| узган елга караганда % | 133,3 | 111,1 |
| 2. Халыкның реаль акча керемнәре, узган елга караганда % | | 104,22 |
| 3. Уртача айлык хезмәт хакы ( бер ел өчен уртача), сум. | 61825,0 | 63897,2 |
| узган елга караганда % | 111,2 | 113,2 |

| Күрсәткечләр | 2024 гыйнвар-июнь | 2024 бәя бирү |
|---|---|---|
| 4. Узган елга караганда реаль хезмәт хакы % | | 106,2 |
| III. Сәнәгать | | |
| Продукциянең мөһим төрләрен җитештерү: | | |
| Нефть, млн.т. | 1,1 | 2,0 |
| III. Агросәнәгать комплексы | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | |
| Ашлык (үлчәмдә эшкәртеп бетергәннән соң), мең. т. | - | 39,8 |
| Ит (тере үлчәүдә терлек һәм кош-корт), мең. т. | 0,7 | 1,5 |
| Сөт, мең т. | 6,7 | 14,0 |
| IV. Кулланучылар базары | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум | 3517,4 | 6107,0 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү күләме, млн. сум. | 198,0 | 374,0 |

Баулы
муниципаль район Советының
2024 елның 12 декабрендәге
281 номерлы карарына
2 кушымта

Баулы муниципаль районының 2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше
ФАРАЗЫ

| Күрсәткечләр | 2025 фараз | 2026 фараз | 2027 фараз |
|---|---|---|---|
| I. Макроикътисадый күрсәткечләр | | | |
| 1.Тулаем территориаль продукт (төп бәяләрдә), млн. сум. | 67967,6 | 71297,0 | 74720,3 |
| 2.Төяп озатылган продукция (эшләр, хезмәтләр) күләме, млн. сум. | 18524,8 | 19895,7 | 21308,2 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, узган елга карата % | 100,7 | 101,0 | 101,2 |
| 4.Барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | 3396,0 | 3504,1 | 3651,1 |
| 5.Финанслауның барлык чыганаклары исәбенә төп капиталга инвестицияләр күләме, млн. сум. | 7026,8 | 7346,5 | 7500,8 |
| 6. Торак йортларны файдалануга тапшыру, мең кв. м | 13,0 | 13,0 | 13,0 |
| 7.Кече һәм урта предприятиеләрнең, микропредприятиеләрне дә кертеп, әйләнеше, млн. сум. | 4255,8 | 4681,4 | 5158,9 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 6262,3 | 6769,5 | 7317,9 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (әлеге чор ахырына), мең кеше | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| 10. Икътисадый актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,16 | 0,16 | 0,16 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | | |
| 1. Айга уртача җан башына керемнәр, сум | 50268,1 | 54273,3 | 58072,5 |
| % узган елга караганда | 108,2 | 107,2 | 107,0 |
| 2. Халыкның реаль акча керемнәре, узган елга караганда % | 103,34 | 103,08 | 102,88 |

| Күрсәткечләр | 2025 фараз | 2026 фараз | 2027 фараз |
|---|---|---|---|
| 3. Уртача айлык хезмәт хакы ( бер ел өчен уртача), сум. | 69303,86 | 75116,99 | 81418,29 |
| % узган елга караганда | 108,5 | 108,4 | 108,4 |
| 4. Узган елга караганда % реаль хезмәт хакы | 103,6 | 103,0 | 102,8 |
| III. Агросәнәгать комплексы | | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | |
| Ашлык (үлчәмдә эшкәртеп бетергәннән соң), мең. т. | 40,1 | 43,2 | 44,5 |
| Ит (тере үлчәүдә терлек һәм кош-корт), мең. т. | 1,7 | 1,8 | 1,9 |
| Сөт, мең т. | 16,8 | 20,3 | 22,6 |
| IV. Кулланучылар базары | | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум | 6418,4 | 6771,5 | 7164,2 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү күләме, млн. сум. | 385,6 | 398,7 | 415,0 |